СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*28 ноябрь, 1997ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 134 (8146)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ЕЛ АХЫРЫ ЯКЫНЛАША: ЭШ ТЕМПЫН КИМЕТМИК!

## Яңалыклар

### Бусагада - Яңа ел

Чыршылы, Кыш бабай һәм Кар кызлы Яңа елга да күп вакыт калмады. Шуны истә тотып, район мәдәният йорты балалар, шулай ук өлкәннәр өчен махсус программа хәзерләүгә кереште. Җырлы - биюле дә, әкиятле дә, бүләкле дә, гомумән, төрле яшьтәге кешеләр өчен кызыклы да булачак ул.

### Бина танымаслык булачак

Районның байтак учреждениеләрен үз эченә сыйдырган район Советы бинасы берничә айдан танымаслык кыяфәткә керер дип көтелә. Бүген биредә капиталь ремонт эшләре башланды. Бу зур эшне үз җилкәсенә алган РСУ төзүчеләре ремонт эшләрен тиз дә, сыйфатлы да итеп башкарырга ниятле.

### Укучылар көчлерәк икән

Узган атнада Якушкино мәктәбендә укытучылар белән укучылар арасында үткән волейбол ярышлары икенчеләрнең җиңүе белән тәмамланды. Укучылар моңа бик шатландылар. Физкультура дәресләрендә нык-лап торып шөгыльләнүләре, кичләрен спорт секцияләренә даими йөрүләре зур йогынты ясаган, димәк.



Гөлия Сатдарованың фермада хезмәт стажы зур түгел: сыер савучы булып эшкә килүенә яңа гына өч ел тулды әле аның. Әмма тырышлыгы, уҗәтлеге башкаларныкыннан һич ким түгел. Ферма мөдире Вәлиәхмәт ага Мостафин да мактап туя алмый үзен, тәртипле дә, эшкә карусыз да, өлкәннәрнең сүзенә колак салучан да икән Гөлия. Шуңа хезмәт күрсәткечләре дә сөенерлек: быелның үн аенда ул хуҗалык сыер савучылары ярышында өченче урын тота.

Рәсемдә: «Дуслык» КХАсы савучысы Г.Сатдарова.

Н.КВАШНИНА фотосы.

## ИСКЕ ЯҢАНЫ САКЛАР

Инде кыр эшләре тәгалләнгән бу вакытта игенчеләр алдында торган көнүзәк бурыч - авыл хуҗалыгы техникасын кышкы саклауга урнаштыру һәм жентекләп дефектлап ремонтларга тотыну. Иртәгәсе көнне кайгыртучы хуҗалыкларда бу юнәлештә эшкә дә тотындылар инде. Җирле мастерскойларда да җанлылык, үзләренең генә хәленнән килмәслек техниканы «Сельхозтехника» район берләшмәсенә дә озаталар. Бүгенге көндә биредә унлап чөгендер яфрагы ургыч, ике КИР -1,5 бар инде, куәтле К - 700ләрен бирегә китерергә җыенучылар да бар. Әмма акционерлык җәмгыятенең ремонт мастерскойлары да, эшче көчләре дә тулы куәтенә файдаланылсын өчен бу бик аз әле. Бигрәк тә бөртекле ашлык комбайннарының берәр генә булуы борчый. Быелгы катлаулы шартларда бик нык тузган чөгендер казу һәм төяү техникасын да быел биредә ремонтлатмыйча булмас. Башка елларда алар гадәттә иң соңгы чиратка калдырыла һәм шуңа күрә ашык - пошык кына ремонтлана, ә бу инде техниканың кырга чыккач еш ватылуына сәбәп була иде. Шуңа күрә быел бу төр техника аерым бер игътибар үзәгендә булырга тиеш дигән бурыч куела. Шикәр чөгендере мәйданнары элеккечә калса да, яңа техника алырга акча җиткерү мөмкин түгел. Шуңа күрә иске яңаны саклар дигән принциптан чыгып эш итмичә булмый. Һәм бу мәсьәләдә хуҗалыкларга да «Сельхозтехника» белән уртак тел табу әмәлен эзлисе.

## «МИНЕМ ГАИЛӘМ»

Шундый исем астында октябрь аенда район мәктәпләрендә рәсемнәр конкурсы үткәрелде. Конкурсның башында торучылар - оештыручылар ТРның балалар һәм яшьләр эше буенча Дәүләт комитеты, мәгариф министрлыгы, «Кадер» иҗтимагый оешмасы һәм яшьләр белән эшләү бүлеге иде.

Ул ике турда - алдан районнарда, аннары республика күләмендә үтте. Район мәктәпләре арасыннан шәһәрнең 1 - 7, Чулпан, Югары Норлат, Якушкино, Биккол, Фома мәктәбе укучылары конкурста актив катнаштылар.

Жюри членнары рәсемнәрнең техникасына, сыйфат ягына гына басым ясамыйча, эчтәлегенә - сюжетына нык игътибар итәләр. Бөтен күрсәткечләр буенча 4 нче мәктәпнең 1"а" классында укучы Рәис Якуповның «Табигатьтә ял» дигән рәсеме алга чыга һәм ул беренче урынга лаек була. II нче урынга 7 нче мәктәпнең («Әкият» балалар бакчасы) 1 нче класс укучысы Андрей Абрамов, ә III нче урынга 4 нче мәктәптән 7 «б» класс укучысы Александр Синяков чыгалар. Җиңүчеләрнең рәсемнәре республика конкурсына тәкъдим ителә, ләкин, кызганычка каршы, аларның призлы урын алудан бик ерак булулары ачыклана.

# Бүгеннән тотынырга кирәк

*(Терлекчелектә яңа технологиягә күчүгә карата)*

Узган ел ноябрь аенда район хакимияте башлыгы барлык хуҗалык рәисләрен дә өч - Мамадыш, Балтач һәм Биектау районнарына алып барып, терлекчелектә хезмәтне оештыруның, малларны карау һәм ашатуның ул районнарда киң кулланылыштагы алымнары белән таныштыруны оештырган иде. Ул чакта безнең җитәкчеләрнең игътибарын тарткан күп яңалыклар арасында Биектау районының «Дружба» агрофирмасында савым сыерларны бәйләүсез асрау, шул исәптән аларны махсус залга кертеп саву технологиясе беренче карашка тиз генә безнең кулдан килмәслек тә эш кебек тоелган иде. Тик, күз курка, кул эшли дигәндәй, ниятләп тотынганда бездә дә теләсә нинди яңалыкны тиз арада кулланылышка кертергә сәләтле җитәкчеләр бар икән шул. Әле яз көне безнең районда булган чагында ук Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев «Киекле» хуҗалыгында абзарларны мөгезле эре терлекләрне бәйләүсез асрауга үзгәртеп коруның уңышлы оештырылганлыгын югары бәяләп, бу эшнең уңай нәтиҗәләренә соклану белдереп киткән иде. Җәй көне исә биредә тагын да кыюрак эшкә тотындылар - савым сыерларны әнә шул биектаулылар үрнәгендә асрауга әзерлек башладылар. Абзарларны үзгәртеп коруны, саву залы төзүне хуҗалык тулысынча үз көчләре белән башкарып чыкты - теләгәч авылның үзендә дә берсеннән - берсе оста куллы егетләр табылды. Ә инде саву залын җиһазлау мәсьәләсендә республикада шушы эшнең пионеры булган махсус оешмага мөрәҗәгать иттеләр, дөресрәге, аларның тәкъдимен ике куллап хупладылар. Шулай итеп, маллар җәйге лагерьдан кайтышка Киекле фермасында 150 сыерга исәпләнгән абзар да, Швециянең «Альфа - Лаваль» фирмасында «Дуовак» системасы буенча ясала торган саву аппаратлары белән җиһазланган саву залы да әзер иде инде.

(Ахыры 3 нче биттә).

## Республика матбугатыннан

● «Болгар - сыра» акционерлык җәмгыятендә эшләнгән «Булгарское» сырасы ачык төстәге сыралар арасында Русиядә иң яхшы дип табылган.

● Татарстан фәннәр академиясенең көньяк - көнчыгыш бүлеге ачылды. Яңа бүлек әлеге бүлектәге фән - техника потенциалын координацияләү һәм аннан нәтиҗәле файдалану, нефть чыгару һәм эшкәртү, машина төзелеше өлкәләрендәге мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итәргә тиеш.

● Казан дәүләт консерваториясе доценты Р.Халиков җитәкчелегендәге татар халык уен кораллары оркестры Франциядә узган XVII халыкара конкурста гран при яулаган.

● «МИ» вертолетларын ясаган конструктор Михаил Мильгә Казан вертолетлар заводында һәйкәл куелачак.

● Киләсе елдан башлангыч сыйныфлар дүрт еллык булачак.

(«Татарстан яшьләре» газетасыннан).

## Хезмәтен хөрмәтләп

Авыл хуҗалыгында озак еллар нәтиҗәле эшләвен искә алып һәм авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көне уңаеннан район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең үсемлекчелек бүлеге башлыгы **НУРГАЛИ МИНГАЛИ** улы **МУСИН** Россия Федерациясенең авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгының Мактау кәгазе белән бүләкләнде.

Районда игенчелек өлкәсендә тәҗрибәле һәм абруйлы белгеч, газетабыз белән дә актив хезмәттәшлек итүче Нургали Мингалиевичны дәрәҗәле бүләккә лаек булуы белән чын күңелдән котлыйбыз.

## Портрет

# Баш инженер баш булгач



Таң әле беленеп кенә килә. Ә идарәнең төп базасында инде халык мыж итә: гараж, мастерскойларның киң итеп ачылган зур капкалары шыгырдавына тимер - томыр шавы, кешеләр тавышы кушыла. Бераздан боларның барысын да мотор гөрелтесе баса. Капкадан бер - бер артлы чыгып китүче техника исә яңа эш көне башлануын искәртә.

Идарәдә планерка топ - төгәл сәгать 6да башлана. Баш һәм урта буын белгечләр, колонна начальниклары катнашында үтә торган бу чарада һәр колонна буенча техниканы линиягә чыгаруга бәйле барлык проблемалар берәмтекләп тикшерелә һәм өйрәнелә, НГДУдан техника сорап кергән заявка да шулардан чыгып канәгатьләндерелә. Идарәнең төп максаты да шул бит. Ә моны тәэмин итү өчен ай - һай күп тырышасы бар.

- Әлеге бурыч, төгәлрәк итеп әйткәндә техник җитәкчелекне тәэмин итү тулысынча баш инженер Сәлахов өстендә,- ди УТТ начальнигы И.Г.Вәлиуллин,- ә ул үз вазифасына җитди карый. Төгәл, үз - үзенә һәм кул астында эшләүчеләргә карата таләпчән. Уртак тел табабыз, фикерләребезнең әлегәчә аерылганы юк.

Техник җитәкчелек дигәннән, бу бик катлаулы һәм транспорт предприятиесендә үтә мөһим процесс. Булган техникага үзвакытында барлык төр техник хезмәтне күрсәтү, запас частьләр белән тәэмин итү, иске узел, агрегатларны төзәтү, торгызуны оештыру, утильләштерү. Техника куркынычсызлыгы, эшләүчеләр өчен шартлар булдыру тагын. Соңгы елларда актуальләшкән экология проблемасы да инженерлык хезмәте өчен күпме өстәмә мәшәкать тудыра - техник хезмәт күрсәтү чорында теге яки бу техниканың әйләнә - тирә юнь мохит өчен зарарлы продукт чыгармавына ирешелерлек итеп көйләп, аңа экология талоны бирү, аны юл үтү озынлыгына карап өстәмә тикшерүне оештыру да мөһим бит. Ә районда иң эре транспорт предприятиесе саналган 497 берәмлек техникалы УТТ өчен моның катлаулылыгын әйтеп торасы да юк. Ярый ла техника бер урында гына тупланган булса. Юк бит, заманында 100 берәмлек техникага гына исәп тотып төзелгән төп база күптән «тараеп» тагын дүрт территориягә бүленеп, башка чыкты. Норлаттан 80 километр ераклыктагы Күтәмәдә, 35 километрдагы Андреевкада да бар алар. Барысында да җылы гаражлар, ремонт базасы булдырылсын, эшләү өчен шартлар тудырылсын... Кул юу урыны да, туалет та кирәк, җылылык та, саф һава да, тиешле дәрәҗәдә яктылык та, кече механизация да керә соңгысына. Дөрес, УТТда боларның күбесенә ирешелде инде. Бер дигән җылы гаражлары, ремонт мастерскойлары, техниканы нәтиҗәле файдаланып, гомерен озайтуга хезмәт итүче башка уңайлыклар да бар. Техник хезмәт күрсәтү өчен барлык шартлары да булган аерым бина булу үзе үк зур нәрсә инде. Техник җитәкчелек дәрәҗәсе дә югары. Техниканы линиягә чыгару коэфициентының 1990 елгы 0,554тән быел 0,570кә җитүе, соңгы елларда кеше үлеменә китергән юл һәлакәтләренең сизелерлек кимүе дә шул хакта сөйли. Әмма баш инженер канәгать түгел әле: ябык типтагы җылы машина юдырту урыны булдырасы, 5 нче колоннада ягулык салу станциясе төзисе, төп базадагысын киңәйтәсе, әлегәчә йомшак саналган баш механик бүлеге эшен җанландырасы бар. Иске узел һәм агрегатларны торгызу буенча эшне көчәйтү дә чират көтми. Шул максатта бина төзелде, хәзер станоклар белән тәэмин итәсе генә калды.

Эшлисе, ясыйсы, табасы, булдырасы... Хәлил Әмирович башында көн саен мең төрле уй, планнар. Билгеләнгән кадәрен үтәп бетерәм дигәндә генә яңалары туа тора. Ни эшләмәк кирәк, дөнья булгач, барысы да була инде аның. Күңел сөендерерлек нәрсәләр дә бар бит эшендә. Әнә, озак еллар даими эшләүче инженер - техник хезмәткәрләр бүген үзләре мөстәкыйль рәвештә эшләп, кыю кадрлар кабул итәрлек дәрәҗәгә җитеп камилләштеләр. Әлегә УТТның ни зур кыскартулары белән, ни эш фронты, ни аз хезмәт хакы яисә аны вакытында алмау белән яманаты чыкканы юк. НГДУның УТТ хезмәт күрсәтә торган 16 цехның ник берсе автотранспортчылар эшенә карата җитди претензия белдермәве дә сөендерә баш инженерны. Ахыр чиктә үз кулы астында эшләүчеләрнең аны оста оештыручы, белемле белгеч буларак хөрмәтләүләрен дә һәрдаим тоя бит ул. Гаиләсендә дә тәртип: арып өенә кайтса, кояштай елмаеп хатыны каршы ала, кызы белән улы муенына сарылалар.

... Кичке эңгер - меңгер. Төп юлдан зур тизлек белән кайтучы машиналар УТТ янына җиткәндә кисәк кенә тизлекләрен «ыргыталар» да мотор гөрелтесенә үзенчәлекле «арыганлык» тоны биреп капкадан эчкә үтәләр: әнә, бүген дә гаражга бер - бер артлы автобуслар, йөк автомашиналары, махсус техника кайтты. Баш инженер һәрвакыттагыча телефон буенча барлык колонна начальниклары белән дә сөйләшеп, «ЧП» булмыйча, барлык техника да исән - имин килеш нарядны үтәп кайтуын белешкәч кенә җаны тынычлангандай булды. Югыйсә, Хәлил Әмирович баш инженер булып эшли башлаганнан бирле карлы - яңгырлы, бозлавыклы көзләрне нәкъ унынчы тапкыр үткәрсә дә, елның әлеге фасылына карата үзенә генә аңлаешлы саклык, күңел тынычсызлыгы тоя ул: бозлавыклар әле башланып кына килә, автотранспортчылар яңа шартларга адаптацияләнмәгәнлектән ул - бу булмасын дип бик борчыла. Шөкер, бүген барысы да тәртиптә. Борчу - мәшәкатьләр тулы тагын бер эш көне узып китте.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: УТТ баш инженеры Х.Ә.Сәлахов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Сез «Дуслык»ка язылдыгызмы?

Соңгы көз ае тәмамланып килә. Сезонлы эшләрнең барысы да башкарылган дияргә була. Район газетасына язылудан башкалары, әлбәттә. Болары да һәр гаиләдә түгелдер, саннар шуны күрсәтә. Әмма бу эшне чигерә килеп ахыр көннәргә кадәр сузучылар барын да беләбез. Тик район хәбәрләре белән танышып барырга теләүчеләр, безгә калса, 26400 сум акча белән исәпләшеп тормаслар, ничек тә газетага язылу чарасын күрерләр дип ышанабыз.

Моңа ышанырга ниг[illegible]дә бар. Район элемтә узелыннан алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, районкага инде 9032 кеше язылырга өлгергән. Шәһәрдә газетаны 3397 кеше алдырачак, калганнары - авыл укучылары. Газетага язылуга йомгак ясарга иртәрәк әле, ул дәвам итә, әмма бүгенгә түбәндәге элемтә бүлекчәләре алда бара: Кормыш - 211 данә, Якушкино - 199, Елаур - 177, Яңа Иглай - 166, Егоркино - 163. Икенче төркемдә - Фома элемтә бүлекчәсе - 161 данә, Төрнәс совхозы һәм Ерепкино - 154шәр данә, Гәйтән һәм Каравыл Тавы 142шәр, Түб[illegible] Чаллы - 141, Урта [illegible]мышлы - 139 данә. Ярты еллык газетаны Чуваш Тимерлегендә - 136, Иске Чаллы һәм Вишневая Поляна да - 134әр, Киекледә - 131, Мамыкта - 122, Заречныйда, Биләр Озерода, Колбай Морасада - 119 - 118әр, Чулпанда - 113 кеше яздырды. Районка Сәләнгеш һәм Андреевка элемтә бүлекчәләренә дә 100дән артык киләчәк. Газетага язылу кампаниясе төгәлләнгәнче без әле тагы яңа укучылар табарбыз дип ышанабыз.

Һәм безнең язмаларыбызны күзәтә барыгыз. Язылу тәмамланганнан соң без иң актив элемтә бүлекчәләрен атаячакбыз. Җиңүчеләрне призлар көтә.

**«Дуслык» редакциясе.**




## Күңел кыңгыраулары

# «Ташлама мине, әтием!»

Алсу яшьтән кызыксынучан, аралашучан булып үсте. Үсә төшкәч аның бик тә яратып башкара торган шөгыле барлыкка килде: ул автографлар җыя башлады. Танылган артистлармы, язучылармы, башка иҗат шәхесләреме яисә күңеленә ятышлы мөхтәрәм өлкән кешеләрме очрый икән - кыз тизрәк олы альбомын тотып аның янына ашыга иде. Тегеләр аксыл бөдрә чәчле, күзләреннән кызыксыну, йөзеннән самимилек бөркелеп торган сөйкемле кызчык үтенеченә каршы тора алмыйча, альбомга ике генә булса да сүз язып имзаларын сырлый иде.

Чираттагы шаян сүз осталары концертына да кызчык альбомын тотып килгән иде. Концерт тәмамлангач, әтисе белән әнисен ишек төбендә калдырды да автограф алырга дип сәхнә артына йөгерде. Кызларының бу гадәтенә күнеп килүче гаилә сабыр гына аны көтә башлады. Әмма кыз нигәдер озаклады. Инде көлешә - көлешә тамашачылар күптән кайтып киттеләр, артистлар да ишеккә юнәлделәр. Әнисе, борчылып, сәхнә артына барырга җыенганда, кызының кычкырып елап йөгереп килүен күреп туктап калды.

- Нәрсә булды, кызым?

Алсу берни әйтерлек хәлдә түгел иде. Күңелле концерттан соң елмая - көлә китеп барган кызны алыштырып куйганнар диярсең: бөтен тәнен калтыравык баскан, күзләреннән елга булып эре - эре яшьләр ага. Килеп җитүгә, әүвәл әнисенә сыенды. Аннан, капылт кына әтисен кочаклап алды да сулкылдый - сулкылдый кабатлый башлады:

- Әтием, мин сине генә яратам. Минем башка әтием юк... Ул миңа кирәкми...

Алсуның сүзләреннән олылар башта аптырап калдылар. Нәрсә булган? Кем кузгаткан нәни кызый күңелендә бу давылны?

Бары бераз тынычлангач кына кызчык вакыйганы сөйләп аңлата алды.

... Алсу сәхнә артына йөгереп менгәндә, таныш түгел бер хатын - кыз аны җиңеннән эләктереп ала да тупас кына әйтеп сала:

- Алсу, нишләп син әтиең белән исәнләшмисең?

Кыз беравык югалып кала, аннан карашын әлеге хатын ишарәләгән якка төби. Анда башын аска ия төшеп, дәшми генә бер ир - ат басып тора. Кыз аңа карый, ә башында һаман бер уй бөтерелә: нишләп бу чит кеше аның әтисе булсын ди? Аның әтисе аста, ишек төбендә басып калды бит. Ул аны мәктәптән каршы ала, авылга әбиләренә кунакка алып кайта, кызның бетмәс - төкәнмәс яңалыкларын сабыр гына тыңлый белә. Алсу яңа киемнәрен кигәч тә иң әүвәл аның каршында бөтерелә, чираттагы «5»лесен әйтеп аны сөендерә. Әнисе белән икәү генә яшәгәндә күңеленнән яшерен кенә әти кеше турында хыялланганда да аның нәкъ шундый булуын тели иде бит ул. Беренче күрүдә үк «күзләре шәфкатьле» дип, күңелендә багышланмыйча яткан бар сабый мәхәббәтен аңа баглады, озак та үтми, аңа үзе өчен бик кадерле сүз белән - «әтием» дип эндәшә башлады. Ә бу авыр карашлы, төссез чырайлы кеше аңа бөтенләй таныш түгел. Дөресрәге, кемнедер хәтерләтә дә кебек, әмма бернинди якынлык, туганлык бөркелми бу томанлы хатирәләрдән.

Кинәт кызны ниндидер куркыныч төш сыман халәт басып ала. Алсу үзенә кызыксынып та, сынап та төбәлгән бу ике кешегә чатнатып җавап бирмәкче, әтисенең башка булуы, аны өзелеп яратуы турында әйтмәкче дә йөгереп китеп бармакчы була. Тик бугазына тыгылган төердән тавышы чыкмый, кинәт авырайган аяклары атламас хәлгә килә. Бары бераздан гына бар җаныннан кузгалган әрнүле елау тышка бәреп чыга, шунда үтеп йөргән артистлар аны тынычландырмакчы булалар...

... Әмма Алсу тиз генә тынычлана алмады. Олылар кызның нәни күңелен яралаган вакыйга урыныннан тизрәк китәргә теләп, урамга ашыктылар. Кыз әтисе белән әнисе кулларына чатырдап ябышып көзге караңгылыктан өйләренә юл алды. Гаиләнең һәр әгъзасы үзенчә авыр уйга чумган иде. Бераз баргач, Алсу туктап калды, әтисенең кулларына ябышып, ялварулы тавыш белән янә кабатлады:

- Әтием, мин сине генә яратам. Син мине беркайчан ташлама, яме...

**С.НУРУЛЛИНА.**

# Руль артында - эмансипэ



Дөньяда елдан - ел машиналар саны арта бара. Прогресс һәм социаль тигезлек эпохасында машина безнең тормышыбызның бер өлеше булып әверелгәч руль артында хатын - кызларны елдан - ел күбрәк күрергә мөмкин. Элек машина мул тормыш күрсәткече булса, хәзер ул хәрәкәтләнү чарасына әверелеп килә. Бу транспорт төренең уңайлыгын аңлап алган хатын - кызлар да руль артында торган саен ныграк, күбрәк урын алалар. Бу процесс бездә чагыштырмача тиз дә бара.

Татарстанда бу күренешне шулай ук күпләп күзәтергә мөмкин. Хатын - кызлар руль артына утыралар, машина сатып алалар, машина йөртергә укыйлар. Кешелекнең көчле яртысы бу урынны артык зур теләк белән бушатмый бушатуын. Әмма ни хәл итмәк кирәк! 1997 нче елда гына да ОСТО район Советында 95 хатын - кыз укып машина йөртүгә хокук бирүче таныклык алды. Укучы хатын - кызлар гадәттә группаның өчтән берен алып торалар.

Практика шуны күрсәтә: хатын - кызлар руль артында күпкә төгәлрәк, саграк, игътибарлырак булалар. Ә инде эчкән баштан руль артына утыру гадәте аларда юк диярлек. Мондый очрак соңгы ике елда безнең районда бер генә тапкыр күзәтелде. ДАИ мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1997 нче елда хатын - кызлар гаебе белән бер генә юл - транспорт фаҗигасе дә булмады, ә шул ук вакытта эчкән килеш руль артына утырган 442 ир - ат автоинспекция тарафыннан тоткарланды.

Дәүләт автоинспекторлары фикере мондый: «Без хатын - кызларның руль артына утыруын хуплыйбыз - алар юл - транспорт фаҗигаләренә сирәк очрыйлар. Һәм ирекле, үз - үзенә ышанган чибәр хатын - кызларны руль артында күрү үзе генә дә күңелле».

Хатын - кыз шоферларның фикере нинди? Әйтүләренә караганда, аларның буш вакытлары арта, ир - ат шофердан бәйлелекләре бетә, үз проблемаларын тизрәк хәл итү җае үсә. Дөрес, ремонт белән кайбер проблемалар бар, әмма алар акрынлап машинаны өйрәнү нәтиҗәсендә, ир - атлар һәм ремонт мастерскойлары ярдәме белән хәл ителерлек.

Ә ир - атларга түземле һәм ярдәмчел булырга гына кала.

**Г.ГЫЙМАЛЕТДИНОВА.**

# Санкт - Петербургта ничә күпер бар?

Бу сорауга төгәл җавапны шәһәрнең үзендә гомер иткән кешеләр дә белмиләр әле. Шунысын әйтергә кирәк: бирeдә күперләр Венеция, Амстердам, Стокгольмдагыдан күбрәк. Санкт - Петербург 42 утрауда утыра, шәһәрнең уннан бер өлешен су били. Бүгенге Петербургны гомуми озынлыгы 300 км булган 86 канал һәм елга бүлгәли. Шәһәрнең өч гасырлык тарихы күпер төзү белән бәйле.

Иң кызыгы шул: патша Петр I башта күпер төзелешенә каршы килгән. Ул шәһәрне зур порт буларак күз алдына китергән, ә күперләр җилкәнле суднолар хәрәкәтенә комачаулык иткән. Петр күперләр төземәскә, ә кешеләрнең үзләрен көймәдә йөрергә өйрәтергә хыялланган.

Нева аркылы беренче даими чуен күпер XIX гасырның уртасында гына төзелә әле. Бу күпер Васильевский һәм Адмиралтейский утрауларын тоташтырган.

Күперләр күпме соң? Шәһәрнең үзәгендә - 315, ә барысы - 539. Тик бу сан үзгәреп тора: искеләре җимерелә, яңалары төзелә. Санкт - Петербург - күперләр музее ул: бирeдә кабатланмас һәм бик сирәк очрый торган күперләр бар.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

***Фома авылында яшәүче кадерле әниебез Розалия Сәлахованы юбилее белән котлыйбыз. Аңа озын гомер, бәхет, сәламәтлек теләп уллары, киленнәре, оныклары.***

## Халык игътибарына!

*Октябрь районы территориаль шифаханә кассасы башкарма дирекциясе районда мәҗбүри медицина страхованиесе полислары бирү тәгәлләнүен хәбәр итә. Әлегәчә полис алмаучы гражданнарның территориаль шифаханә кассасына түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итүләрен сорыйбыз: Норлат шәһәре, 60 лет Октября ур., 16а (ДОСААФ бинасы). Үзегез белән паспорт, 16 яшькә җитмәгән балалар өчен туу турында таныклык булуы шарт. Районның дәвалау учреждениеләрендә медицина хезмәте күрсәтү катгый рәвештә полис нигезендә генә алып барыла. Татарстан Республикасында һәм аннан читтә медицина хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча территориаль шифаханә кассасы башкарма дирекциясенә мөрәҗәгать итәргә.*

Тел.: 2 - 18 - 15.

# Сак йөрегез!





Узган 10 айда Октябрь районында юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 4627 очрагы теркәлде. Алар арасында исерек килеш руль артына утырган - 442, тизлекне арттырган - 296 транспортчы һәм юл йөрү кагыйдәләрен бозучы 48 җәяүле туктатылды. 32 юл - транспорт фаҗигасе булды, анда 30 кеше яраланды, 8 кеше үлде.

Юлда авария гадәти хәлгә әверелә, күп шоферлар бәлага таручы яныннан битарафлык белән узып китәләр. Барлык транспорт фаҗигаләренең 75 процентка якыны юл йөрү кагыйдәләрен бозудан килеп чыга. Һәр авария тәҗрибәсенә дә бәйсез рәвештә теләсә кайсы шофер өчен сабак ул.

Башкалар хаталарын да өйрәнү - машина йөртү классслылыгын күтәрүнең төп ысулларыннан берсе. Җимерелгән машина шоферга үз машинасын сак һәм карап йөртү өчен психологик этәргеч бирергә тиеш. Моннан тыш ул аварияләр булган очракта үзеңне ничек тотарга кирәклеген дә аңларга булыша.

**ГАИ.**

**Рәсемдә: чит хатаның аянычлы нәтиҗәләре.**

# Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч рәвештә кулланышта булган йокы гарнитурасы, «Свияга - 404» суыткычы, Югославиядә эшләнгән ир - атлар кайры туны, бәясе - килешү буенча.** Тел.: 5 - 18 - 36.

***

**Ашыгыч рәвештә кулланышта булган ике камералы «Мир» суыткычы һәм антресольсез өч ишекле шифоньер. Бәясе килешү буенча.** Тел.: 5 - 25 - 85.

***

**Чистарту корылмалары районында гараж.** Адрес: К.Маркс ур., 27 - 7.

***

**Ак төстәге ВАЗ - 21061, бәясе 20 млн. сум, сатулашу урынлы.** Адрес: К.Маркс проспекты, 3 - 11.

***

**4 бүлмәле фатир.** Адрес: Карл Маркс проспекты, 4 - 4.

***

**Ашыгыч рәвештә тентлы УАЗ - 33036, «люкс». 1997 нче елның сентябрь ахырында чыккан.** Адрес: Советская ур., 183 - 86, 16 сәг.тән соң.

***

**15 тонна йөк күтәрешле электроталь.** Бәясе 1,5 млн. сум. Тел.: 5 - 21 - 94.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Самара шәһәрендәге бер бүлмәле фатирны (16 кв. метр) Норлаттагы шундый укка алыштырам.** Арадашчы тел.: 2 - 19 - 54.

***

**Төрле зәвыкта һәм төрле бәягә Яңа ел бүләкләренә сез «Берт» кибетенә заказ бирә аласыз. Оешма һәм предприятиеләрдән дә заявкалар кабул ителә.** Безгә рәхим итегез!

***

**Гыйматдинов исемендәге урамда 126 нчы йорт фатирга алыштырыла.** Адрес: Садовая ур., 2а, 56 нчы фатир.

***

**Октябрь райпосы азык комбинатына даими эшсыек ягулыкта пар казаннары операторлары (тиешле белемнәре булу шарт) кирәк. Белешмәләр өчен директорга мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 2 - 21 - 15 (8 сәг.тән 17 сәг.кә кадәр).

***

**Яшәп тору өчен фатир кирәк.** Тел.: 5 - 24 - 29.

***

**«Ак Барс» банкы клиентлары игътибарына! 1997 нче елның 25 нче ноябреннән «Ак Барс» банкы промышленность - төзелеш банкы бинасында булачак.** Адрес: Норлат шәһәре, Школьная ур., 10.

## Игътибар: яңа товар

**Безнең кибет ел ахырында шәһәр һәм район халкына Россиянең иң яхшы суыткычы - «Stinol» алырга тәкъдим итә. Сез бездә аның 7 моделен таба аласыз. Моннан тыш, Европада танылган «Аристон», «Ардо», «Индезит» кер юу машинасы һәм газ плитәләре бар. Гарантия һәм китереп бирү. Һәрвакыттагыча, әйдәп баручы фирмалар теле видеоаппаратураларының күп төре. Без сезне «Техника» кибетендә һәм промышленность базарында шимбә һәм якшәмбе көннәрендә көтәбез.**

## *Хөрмәтле«Девон - Кредит» банкы акционерлары!*

**«Девон - Кредит» акционерлык банкы 1997 нче елның 6 ае өчен (апрель - сентябрь) бер акциягә 10 мең сум исәбеннән гадәти исемле акцияләргә дивидендлар түләү башлануын хәбәр итә.**

**Дивидендларны түләү рәвеше:**

**- физик затларга акчалата яки акционер гаризасы нигезендә аның шәхси счетына күчерелә;**

**- юридик затларга - расчет счетына күчерелә.**

Түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә: Норлат шәһәре, Советская ур., 179, «Девон - Кредит» акционерлык банкы филиалы.

## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көне 5, 19 декабрьләрдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.